килгән шәригать кыямәт көненә кадәрге вакыт өчен билгеләнгән. Дөньядагы нинди генә үзгәрешләр булуга карамастан, диндә бернинди дә үзгәрүләр булырга тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә «әл-Маидә» сүрәсенең 3 нче аятендә әйтә: *«Бүген динегезне камил кылдым һәм сезгә Үземнең нигъмәтемне тәмам кылдым, һәм динегезнең ислам дине булуы белән риза булдым».*

Бүген ислам динен заманага яраклаштыручы галимнәр бик күбәеп китте. Бер яклап, дөньяви галимнәр ислам динен үзгәртергә кирәк, дип йөрсәләр, икенче яклап, мөселманнардан саналып йөрүчеләрнең кайбер наданнары, 100 елга бер динне турылаучы килачәк дип, үзләрен шул турылаучыга санап, үзләренчә яңа шәригать төзеп, тырышып-тырышып, бөтен кешене шул үзләре төзегән шәригать тирәсендә туплап йөриләр.

Бу ике төркемнең бер-берсенә бернинди охшашлыклары юк кебек күренсә дә, асылда алар бер эшне башкаралар: исламга ревизия ясарга, моңарчы булган галимнәрнең фикерләрен, карашларын сызып ташлап, шәригатьне яңадан төзергә тырышалар. Икесе дә: «Бүген дөнья үзгәрде, кешелек фән һәм техник яктан алга китте, бүгенге тормышта Коръәнгә, сөннәтләргә караш яңача булырга тиеш, элекке галимнәрнең аңлатулары бүгенге көн таләпләренә туры килми», – диләр. Хәтта кайберләре Пәйгамбәребез хәдисләрен тәнкыйтьләүгә хәтле барып җитәләр. Әйтерсең, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышның шулай булачагын белмәгән һәм Аллаһы Тәгалә дә Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмне пәйгамбәр итеп җибәргәндә, аңа шәригатьне шул чор өчен генә билгеләгән.

Кыямәт көненең хуҗасы булган Аллаһы Тәгалә шәригатьне йөкләгәндә, әлбәттә, булачак цивилизацияләрнең барысын да, техник-технологик яктан алга китүләрнең барысын да күз алдында тота. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә җәннәтне һәм җәһәннәмне, аларга кертелгән кешеләрне күрә. Ул кешеләр нинди генә цивилизациядә булуларына карамастан, аңа күрсәтеләләр. Шуңа күрә дә Рәсүл Әкрам үзенең хәдисләрендә җәннәтне, җәһәннәмне тасвирлый, анда ирешә торган кавемнәрнең, халыкларның сыйфатларын әйтә. Үзеннән соң килә торган халыкларның ничек юлдан язачакларын, аннан саклану чараларын искәртә, кайбер кавемнәрнең үзләренә яхшы сыйфатлар алып, асылда кяфер булып калуларын, күп халыкларны үзләре артыннан ияртеп ялган юлга, шайтан юлына кертәчәкләрен әйтеп кисәтә. Мәсәлән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм римлыларның варисларыннан булачак халыкны тасвирлап болай ди: «Аларның 4 сыйфатлары булыр. Алар сынауларда моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә сабырлык күрсәтәләр, бәла-казалардан соң тиз аякка басалар, чигенгәннән соң, башкалардан тизрәк яңадан үзләренең урыннарына кайталар һәм ярлыларга, ятимнәргә, мохтаҗларга башкалардан яхшырак ярдәм итәләр һәм аларның бик күркәм бишенче сыйфатлары бар: алар гаделсезлектән башкаларга караганда да читтәрәкләр».

Шушы сыйфатлары европалыларны дөньялыкта югары дәрәҗәләргә ирештерде һәм, чынлыкта, алар римлыларның варислары булып торалар. Кем генә кызыкмый аларның бу сыйфатларына. Хәтта мөселманнар да үзләренең вәгазьләрендә күпләргә мисал итеп аларны куялар. Әмма бу, сарык тиресе ябынган бүре кебек, өстенә яхшы сыйфатларга ия булган кием кигән, асылда имансыз бер кавем. Ул кавем, ягъни Европа цивилизациясе, фән һәм техника өлкәсендә искиткеч уңышларга ирешүенә карамастан, бөтен кешелекне кайгы-хәсрәт, ач-күзлелек, ялгызлык һәм рухи бушлык упкынына алып килде.

Бөтен дөньяны түбәнчелектән, кешелексезлектән алып чыккан ислам өммәте ничә йөз еллар дөнья белән идарә итеп, бөтен дөньяның байлыгын үз кулында тотып, күп халыкларга үрнәк булып торды һәм ахырда тәкәбберләнеп, гыйбадәттән читләшеп, дөнья байлыгына кереп батты, алга үсештән туктады. Шушы вакытта тышкы яктан исламның бөтен күркәм сыйфатларын үзенә алырга тырышып, эчке яктан кәферлектә, имансызлыкта булган бер цивилизация, Европа цивилизациясе барлыкка килде. Тышкы дөньяларына кызыгып, күп мөселманнар аларга иярделәр. Әйтерсең, Европа цивилизациясе кыяфәтендә Дәҗҗал дөньяга килде. XX гасырда күпме халкы мөселман булган дәүләтләр алар артыннан ияределәр, хәлифәт бетте, мөселманнар таркалдылар. Элек алар дөнья белән идарә иткән булсалар, хәзер алар шушы европалылар кул астында калдылар һәм бүгенге көндә дә бу бәйлелектән чыга алганнары юк.

Нигезе матди байлыкка корылган Европа цивилизациясе бүген ныгыды. Бөтен дөньяны үзенә каратты, һәм ул үзен дөньяларның патшасы, халыкларның язмышы белән уйный алырлык дәрәҗәдәге зат итеп хис итә башлады - аның чын йөзе ачылды. Бүген анда үтереш, зина, ялган хөкем сөрә, Аллаһы Тәгалә кушканнар тыела, тыйганнар таләп ителә. Халыклар алдана торган дөнья шул инде ул.

Аллаһы Тәгалә «әл-Кыйтәл» сүрәсенең 36 нчы аятендә әйтә: *«Чынлыкта, бу дөнья - уен һәм шаяру гына».* Дөнья ул чүлдәге мираж кебек: алдында төрле сарайлар, бакчалар күрәсең, төрле планнар корасың, бакчадагы җимешләргә менә-менә кул җитәр кебек һәм син алып ашарсың кебек, әмма барасың-барасың, тик барып җитә алмыйсың, корган планнар үтәлми, ачыгып, сусап, шул чүлдә үләсең. Дөнья ул матур төш кебек: иң татлы, кызык җирендә уянасың һәм үзеңдә төштә күргән нәрсәләрнең юк икәнлеген күрәсең.

Бүген үзләрен мөселман дип санаучы күпләрнең күңелләре дөньялыктан аерылмаган. Телдә икесен дә, ягъни динне дә, дөньяны да тигез алып барырга кирәк, диләр.



# Пәйгамбәребез (с.г.в.с.) туган көн

*Пәйгамбәребез туган көн —*
*Мөбарәк көннәрдәндер.*
*Аллаһы Тәгалә илчесе —*
*Иң сөеклеләрдәндер.*

*Пәйгамбәребез дөньяга килгән*
*Рабигуль-әүвәл аенда.*
*Ислам дөньясында бу бәйрәм*
*Күчә буыннан-буынга.*

*Коръән иңгәч җир йөзенә,*
*Ислам дине таралган.*
*Салаватлар әйтер өчен,*
*Бу көн бәйрәм саналган.*

*Аллаһы Тәгалә илчесе буларак,*
*Туры юлны күрсәткән.*
*Ислам кануннары буенча*
*Изгелеккә өйрәткән.*

*Гадәткә кертеп калдырган*
*Садакалар бирүне.*
*Кул күтәреп сорыйк, телик*
*Җәннәтләргә керүне.*

*Гамәлләр кылып үтәп барыйк*
*Пәйгамбәребез сөннәтен.*
*Кыямәт көнне аңларбыз*
*Безгә булган хөрмәтен.*

*Аллаһыга тугры булып,*
*Гыйбадәтләр күп кылыйк.*
*Тәмуг утында янмабыз,*
*Һәр көн теләктә булыйк.*

*Фани дөнья безне алдый,*
*Тәүбә-истигъфар кылыйк.*
*Ахыр йортыбыз бакыйдыр,*
*Тәүфыйк-һидаят сорыйк.*

*Зекер-салаватлы булсак,*
*Хисапланыр кылган эш.*
*Иманлы затлардан булсак,*
*Оҗмах бирер сөенеч.*

**Саимә МОРЗАХАНОВА.**

*Гали авылы,*
*Похвистнево районы.*

# Изге теләк

Теләкләрнең була күп төрлесе,
Теләк бит ул кеше язмышы.
Ходаемнан елап сораганда,
Теләк булыр җәннәт ачкычы.

Әткәй-әнкәйләргә мәңге рәхмәтле без,
Яшәр өчен гомер биргәнгә.
Ходаема шөкерана кылыйк
Ислам динен бүләк иткәнгә.

Шөкерана кылыйк бер Ходайга
Яшәгәнгә якты дөньяда.
Балаларга шәфкать, мәрхәмәтлек сорыйк,
Калдырмасын безне далада.

Иртән тору белән шөкерана кылыйк
Сулар өчен һава, эчәр өчен суыбыз булганга.
Авыз тутырып ипекәй ашыйбыз бит
Бер Ходаем юмарт булганга.

Илаһым! Бир Син илгә тынычлыклар,
Патшаларга җәлләмә Син акыл-фигыльне.
Күрсәтмә балаларыбызга ятимлекне,
Барчабызга бирче тәүфыйкны.

Олыларны һәрчак хөрмәт итеп,
Насыйп ит син безгә яшәргә.
Барча туганнарны бәхилләтик,
Бурычларны тырышыйк үтәргә.

Изге теләкләрне бик күп телик,
Кабул булсын иде, илаһым.
Ата-ана бәхиллеген алыйк,
Гафу итәр безне Ходаем.

**Халидә ШӘКҮРОВА.**

Камышлы районы,
Камышлы авылы.




**Намазны тәмамлагач, дога һәм зикер кылганда ике кулны күтәреп ничек тотарга? Кулны дога кылу өчен нинди шартлардан соң күтәрергә ярый?**

Дога кылучы кулын күтәрмәсә дә, догасы дога булып китәргә мөмкин. Дога кылганда "Әллаһүммә" дип башлыйбыз, "Бисмиллә" әйтмибез бит. Аллаһы Тәгаләне ничек зикер итсәң дә дөрес. Аллаһы Тәгалә әйтә: *"Әгәр бәндә Миннән хаҗәтен сорап догага кулын күтәрсә, Мин аның кулын буш кайтарырга оялам",* - ди. Кулны җилкәдән югары күтәрү килешми, кендектән аста да була алмый. Иң күркәме: күкрәк турысында тоту.

*("Татар мөселман календаре"ннан)*